КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 июль г.Казань № 614

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формаларын раслау хакында» 2018 ел, 19 апрель, 268 нче карары белән расланган җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативларының эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формаларын раслау хакында» 2018 ел, 19 апрель, 268 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 15 апрель, 285 нче;

2019 ел, 24 май, 435 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктның 2 графасында «3 статьясындагы $1^1$, 2 өлешләр,» сүзләреннән соң «$3^2$,» саннарын өстәргә;

5 нче пунктның 2 графасында «3 статьясындагы $1^1$, 2 өлешләр,» сүзләреннән соң «$3^2$,» саннарын өстәргә;

11 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин